# *Сабирова Дания Мөхәммәтҗан кызы*

*Мин, Сабирова Дания Мөхәммәтҗан кызы, 1939 нчы елның 2 нче маенда Ювас авылында тудым. Сугышка әтием белән олы абыем китте. Әти сугышта калды, "хәбәрсез югалды" дип хат килде. Ә 1924 елгы абыем яраланып кайтты. 1929 елгы абыем армиягә бармады.*

*7 сыйныф белем алдым, 4 сыйныф Ювас та укып, 3 елны 7 еллык Битаман мәктәбендә укып бетердем. 42 ел хезмәт стажым бар. Сыер савучы булып эшләдем.*

*Сугыш башланганда мин 3 яшьлек бала идем. Әти сугышка киткәндә " әти, озак торма" дип озатып калганмын. Абыем сугыштан 1946 елның маенда кайтты, мин ул чакта укырга кермәгән идем әле. 7 яшьлек бала идем.*

*Әнигә 3 бала калганбыз, кычытканын да, кузгалагын да ашаттылар, язын кукәрин дә ашадык. Абыем белән әнием туендырган инде безне. Урманнан утынын да ташыганнар, шуны өйгә ягып җылытканнар. Бәрәңге яфрагы җыеп, аш пешерә идек. Ул вакытларны искә төшергәч, әле дә күңелем бик әрни шул.*

*Шушы тормышыгыздан, Ходай тәгалә аермасын, яшьләр бәхетле, тәүфыйкълы булып үссеннәр.*

